**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1042

г. Казань

2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнарны;

2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) күрсәтә торган амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күләмнәре нормативларын.

2. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1042.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1042 нче
карары белән расланды

2016 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар

| Т/с | Диализ хезмәтләре күрсәтү, гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) исеме | Норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| 1. | Түбәндәгеләр күрсәтә торган амбулатор гемодиализ хезмәтләре: | |
| 1.1. | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академик Королев урамы, 4 нче А йорт адресы буенча урнашкан җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыять үзәге | 1 процедурага 70,0 еврога һәм 1 245 сумга эквивалент сумма |
| 1.2. | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 2 нче йорт, литер Ж адресы буенча урнашкан җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыять үзәге | 1 процедурага 70,0 еврога һәм 1 120,5 сумга эквивалент сумма |
| 2. | Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре өлкәннәргә күрсәтә торган перитонеаль диализ хезмәтләре | 1 пациентка 887,47 мең сум |
| 3. | Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре балаларга күрсәтә торган перитонеаль диализ хезмәтләре | 1 пациентка 1 379,55 мең сум |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1042 нче
карары белән расланды

2016 елга гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга күрсәтә торган амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күләмнәре нормативлары

| Т/с | Абулатор гемодиализ хезмәтләре һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтә торган гемодиализ үзәкләре (бүлекләре) исеме | Үлчәү берәмлеге | Диализ хезмәтләре күрсәтү саны |
|---|---|---|---|
| Амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 1. | Җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең гемодиализ үзәкләре, шул исәптән: | процедура | 70 512 |
| | Казан шәһәрендәге, Академик Королев урамы, 4 нче А йорт адресы буенча урнашкан | процедура | 39 312 |
| | Казан шәһәрендәге, Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 2 нче йорт, литер Ж адресы буенча урнашкан | процедура | 31 200 |
| Перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 1. | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гемодиализ бүлеге | пациент | 13 |
| 2. | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» Татарстан Республикасының дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гемодиализ бүлеге | пациент | 5 |
| 3. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | пациент | 2 |

_______________________________